Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Әсәй авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Әсәй авылы № 24-8 16 февраль 2016 ел.

Әсәй авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча,җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Әсәй авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Әсәй авылы башлыгының 2016 елның 29 гыйнварында чыккан 2 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Әсәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 гыйнварында чыккан 23-7 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Әсәй авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 17 апрель 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Әсәй авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узара салым җыю белән килешәсезме. Узара салым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - авыл җирлегенең торак пунктларын пожар куркынычсызлыгының төп чаралары белән тәэмин итүгә (Әсәй авылындагы янгын ДЕПОсын ремонтлау һәм карап тотуга), үзара салым акчасының 99 мең сум күләмендә;
   - авыл җирлеге халкының ялын оештыруга һәм җирлекнең мәдәният оешмалары тарафыннан шартлар тудыру, (Митрәй авыл мәдәният йортына бильярд өстәле комплекты сатып алуга), үзара салым акчасының 16 мең сум күләмендә;

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Совет рәисе урынбасары: Г.Ф. Идиятова